ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2024 елның 18 ноябре** **Чистай шәһәре** **№ 540**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2026 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» программасында катнашучы табиб-белгечләрне матди кызыксындыру максатларында айлык түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2023 елның 12 октябрендәге 616 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 29 июнендәге 433 номерлы карарын, «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 29 июнендәге 433 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 октябрендәге 615 номерлы Башкарма комитет карарын, «2022-2026 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» программасында катнашучы табиб-белгечләрне ай саен кызыксындыру максатларында айлык түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2023 елның 12 октябрендәге 616 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 7 пунктчасы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2022-2026 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» программасында катнашучы табиб-белгечләрне ай саен кызыксындыру максатларында айлык түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 Гомуми нигезләмәләр бүлегендә 1.2 пунктның 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы һәм Чистай муниципаль районы территориясендә урнашкан торак урыннар (торак урыннарга гомуми өлешле милек хокукындагы өлешләр), табибның һәм аның гаилә әгъзаларының торак урыннан файдалану хокукы булмау, шулай ук табибның һәм аның гаилә әгъзаларының Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә торак бинадан файдалану хокукы яисә файдалануда торак урыны (торак биналар) мәйданы белән тәэмин ителү йә табибның һәм аның гаилә әгъзаларының торак биналар милкендә булган очракта, гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган өлеше (торак урыннарга гомуми өлешле милек хокукындагы өлешләр), Чистай муниципаль районында торак урынны наем шартнамәсенә бирү буенча торак урыны бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен билгеләнгән нормадан азрак булу.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов